ГЛАВА КАНАШСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
Ул. Центральная, д.4, д. Канаш, 422584

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮГАРЫ ОСЛАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ КАНАШ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ
Үзәк ур., 4 нче йорт, Канаш авылы, 422584

Тел.: (84379) 36-7-45, факс: (84379) 36-7-45.

№ 4-1

Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Канаш авыл җирлеге Нижнее Озеро авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында
КАРАР

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003нче елның 6нчы октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56нчы статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында «2004нче елның 28нче июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35нчы статьясы нигезендә, 2020нче елның 24нче октябрендә узган «2021нче елда Югары Ослан муниципаль районы Нижнее Озеро авыл җирлегендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 300 сум күләмендә үзара салым кертүгә килешәсезме?" дигән сорау буенча үткәрелгән халык җыены нәтиҗәләре буенча беркетмә төзелде. Гражданнар җыенының үткәрелгән этаплары нәтиҗәләре буенча йомгаклау беркетмәсенә сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 130 граждан, җыенда катнашучылар саны 96 граждан кертелгән.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«Әйе» позициясе өчен халык җыенында катнашучы 96 кеше тавыш бирде,

«Юк» позициясе өчен халык җыенында катнашучы 0 кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар итте:

1. Югары Ослан муниципаль районы Канаш авыл җирлегенең Нижнее Озеро авылында гражданнар җыенын булып узды, халык җыены нәтиҗәләре дөрес дип таныргa.

2. «Сез 2021нче елда Югары Ослан муниципаль районы Канаш авыл җирлегенең Нижнее Озеро авылында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 300 сум күләмендә үзара салым кертергә һәм алынган акчаларны авыл җирлеге Башкарма комитеты җитәкчесе карары белән билгеләнгән ташламалардан тыш, җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерергә килешәсезме?: – "Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Канаш авыл җирлегенең Нижнее Озеро авылында чишмәләрне төзекләндерү".

3. Югары Ослан муниципаль районы Канаш авыл җирлегенең Нижнее Озеро авылында узган гражданнар җыены нәтиҗәләрен Канаш авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында игълан итәргә

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Канаш авыл җирлеге башлыгына Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына җибәрү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче: Н. Н. Вальков